Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Иске Шөгер авыл җирлегенең
Иске Шөгер торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2024 елның 2 апреле № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгеравыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгерторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту, юлларны грейдерлау, юл кырыйларын чүп үләнен чабу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (койма буяу, чәчәкләр һәм куаклар утырту, С. Садри урамындагы һәйкәлнең үләнен чабу; Яшьләр урамындагы «Яшьлек» паркының үлән чабу, чәчәкләр һәм куаклар утырту);

3) тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру)ремонтлау;

4) ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (коры

һәм чүп үләнен чабу, зират территориясендә иске авария агачларын һәм куакларны кисү, килешү буенча түләү).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 йорт, Совет урамы, 3 йорт, М. Җәлил урамындагы 33 нче йорт янында балалар бакчасы бинасы, Яңа Шөгер авылы, Гагарин урамы, 1/а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова